# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Уразай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11 март 2022 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставы нигезендә 2022 елның 11 нче мартында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«"Сез, Себер язвасы белән авырган маллар күмелгән үләт базын ремонтлау турындагы мәсьәләне, 2021 елның 17 декабрендәге Уразай авылы гражданнар җыенының 1 нче, 2 нче карарларыннан төшереп калдырырга ризамы?"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 550 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 280 .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 280, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Уразай _авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дорес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:
«Сез, Себер язвасы белән авырган маллар күмелгән үләт базын ремонтлау турындагы мәсьәләне, 2021 елның 17 декабрендәге Уразай авылы гражданнар җыенының 1 нче, 2 нче карарларыннан тошереп калдырырга ризамы?"

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 кон эчендә, Уразай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү очен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы ____________ А.М.Шәрифуллина
Уразай авыл җирлеге башлыгы (имза) (имза расшифровкасы)

УРАЗАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ